КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 апрель г.Казань № 307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк әһәмиятенә яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 март, 192 нче; 2015 ел, 20 июнь, 445 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1147 нче, 2020 ел, 6 июль, 552 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль

юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләренә, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

Татарстан Республикасы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташыганда Сәнәгать өлкәсендә Россия икътисадын барлыкка китерүче оешмалар исемлегенә керүче (Санкцияләр шартларында Россия икътисады үсешенең тотрыклылыгын арттыру буенча Хөкүмәт комиссиясе финанс секторының һәм икътисадның аерым тармакларының тотрыклылыгын арттыру буенча ярдәмче комиссия утырышының 2022 елның 24 мартындагы 1кс номерлы беркетмәсе белән расланган) Татарстан Республикасы оешмаларының транспорт чаралары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2022 ел, 7 март, 1992 нче карары нигезендә кертелә торган хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертү чорында күчәр йөкләнешенең иң чик мөмкин булган күрсәткечләре күрсәткечен арттырганда) китерелә торган зыян күләме хәрәкәтне вакытлыча чикләү керткәндә кулланыла торган 2 нче таблицада билгеләнгән күрсәткечнең 0,3 енә тигез.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин